Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Советының бишенче чакырылышының бишенче утырышы

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советы карары

25 декабрь, 2025 ел № 29

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның 2025 елгы фаразлау планын (программасын) үтәү йомгаклары турында хисапны раслау хакында

«Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы, «гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының «2023 елга Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның Фараз планын (программасын) раслау турында» 2023 елның 18 маендагы 238 номерлы карары (2023 елның 7 декабрендәге 291 номерлы, 2025 елның 22 маендагы 407 номерлы карары белән) нигезендә **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карар кабул итте:**

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруныњ Фараз планын (программасын) үтәү йомгаклары турында хисапны 2025 елда расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының җирлекләрнең җирле үзидарә органнары белән үзара эшчәнлек, законлылык, хокук тәртибе һәм регламенты буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Питрәч муниципаль районы башлыгы Р.Ә. Сөләйманов

Татарстан Республикасы Питрәч
муниципаль районы Советы
карары белән расланды
25 декабрь, 2025 ел № 29

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның Фараз планын (программасын) үтәү йомгаклары турында хисап

2025 елда муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру «2023-2025 елга Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның Фараз планын (программасын) раслау турында» Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының 2023 елның 18 маендагы 238 номерлы карары (Советның 2023 елның 7 декабрендәге 291 номерлы, 2025 елның 22 маендагы 407 номерлы карарлары белән расланган үзгәрешләре белән) нигезендә гамәлгә ашырылды.

Питрәч муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның төп бурычы муниципаль милек структурасын Питрәч муниципаль районы җирле үзидарә органнары вазыйфаларын (вәкаләтләрен) һәм бурычларын тәэмин итү өчен файдаланылмый торган һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен билгеләнмәгән муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру исәбенә оптимальләштерү.

2025 елга Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның фаразлау планына түбәндәгеләр кертелгән:

- күчемле мөлкәтнең 9 объекты;
- күчемсез мөлкәтнең 16 объекты.

Хосусыйлаштыру объектларын сатуның башлангыч бәясе «Россия Федерациясенең бәяләү эшчәнлеге турында» 1998 елның 29 июлендәге 135-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә билгеләнгән базар бәясеннән чыгып билгеләнә.

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы бюджетына үтәлүдән 3 304 200,00 сум күләмендә акча керде.